«Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Югары Акхуҗа авыл җирлегенең Берләш авылында халык җыены нәтиҗәләре һәм 2022 елда үзара салым кертү турында» 2022 елның 02 декабрендәге 1 номерлы Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Югары Акхуҗа авыл җирлегенең Берләш авылында гражданнар җыенының карары

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә

«Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Югары Акхуҗа авыл җирлегенең Берләш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән (көндезге формада белем алучы студентлардан, балачактан инвалидлардан, коляскада йөрүче инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, күп балалы гаиләләрдән тыш) 500 (биш йөз) сум күләмендә 2023 елда үзара салым кертүһәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча:

• Берләш авылы территориясен төзекләндерүне оештыру.

эшләрен башкарырга юнәлдерү белән килешәсезме?» дигән мәсьәлә буенча 2022 елның 02 ноябрендә Берләш авылы гражданнары җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 5кеше кертелгән, тавыш бирүдә кеше катнашкан гражданнар саны 3 кеше .

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен җыенда 3 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Югары Акхуҗа авыл җирлегенең Берләш авылында халык җыенын узган дип, халык җыенының нәтиҗәләре дөрес дип танырга.

2. «Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Югары Акхуҗа авыл җирлегенең Берләш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән (көндезге формада белем алучы студентлардан, балачактан инвалидлардан, коляскада йөрүче инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, күп балалы гаиләләрдән тыш) 500 (биш йөз) сум күләмендә 2023 елда үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча:

• Берләш авылы территориясен төзекләндерүне оештыру эшләрен башкарырга юнәлдерү белән килешәсезме?» дигән мәсьәлә буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Югары Акхуҗа авыл җирлегенең Берләш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән (көндезге формада белем алучы студентлардан, балачактан инвалидлардан, коляскада йөрүче инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, күп балалы гаиләләрдән тыш) 500 (биш йөз) сум күләмендә 2023 елда үзара салым кертергә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча:

• Берләш авылы территориясен төзекләндерүне оештыру эшләрен башкарырга юнәлдерергә.

4.Әлеге карарны мәгълүмат стендындлары аша халыкка белдерергә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

Югары Акхуҗа авыл җирлеге Башлыгы З.Я.Юзеев